**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Кәкре Күл авыл җирлеге составына керүче Аксубай Урман заводы бистәсендә гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**КАРАР**

**№ 1** **17 ноябрь 2022 ел.**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131 - ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасын даҗирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 24 «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Кәкре Күл авыл җирлеге Советының 05.11.2019 ел, № 115 карары белән» гә нигезләнеп: 2022 елның 17 ноябрендә Аксубай муниципаль районы Кәкре Күл авыл җирлегенең Аксубай Урман заводы бистәсендә « I төркем инвалидлары, Бөек Ватан сугышы ветераннары, көндезге уку формасы буенча укучы студентлар, Россия Федерациясе Хәрби хезмәтенең сроклы хезмәтендә, Украинада спец. операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш «2023 елда Аксубай муниципаль районы Кәкре Күл авыл җирлегенең Аксубай Урман заводы бистәсе территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 700 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы?, һәм алынган акча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерергә ризамы; сорауы белән Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Кәкре Күл авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында«, гражданнар җыены нәтиҗәләре беләнберкетмәсе төзелде.

**Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:**

**- Урам яктыртуын оештыруны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).**

**- Аксубай Урман заводы территориясендә үсентеләр чабу (ягулык-майлау материаллары сатып алу).**

**Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;**

**- Кышкы чорда автомобиль юлларын карап тоту (ягулык-майлау материаллары сатып алу, урамнарны кардан чистарту, килешү буенча эшләр өчен түләү).**

“РИЗА” “КАРШЫ” “ТЫЕЛДЫМ”

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 17 граждан, җыенда катнашучылар саны 10 граждан кертелгән.

Халык җыенында катнашучыларның ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

"Риза» позициясе өчен 10 граждан тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен 0 граждан тавыш бирде;

«Тыелдым» позициясе өчен 0 граждан тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Кәкре Күл авыл җирлегенең Аксубай Урман заводы бистәсендә узган халык җыенын халык җыены нәтиҗәләре - чын мәгънәсендә дип танырга.

2. " I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, Россия Федерациясе Хәрби хезмәтенең хәрби хезмәткәрләреннән һәм Украинада спецоперациядә катнашучылар, аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 2023 елда Аксубай муниципаль районы Кәкре күл авыл җирлеге Аксубай Урман заводы бистәсе территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 700 сум күләмендә үзара салым кертү турында килешәсезме һәм алынган акча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне башкару буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерергә ризамы: дигән сорау буенча КАРАР КАБУЛ ИТЕЛДЕ.

**Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:**
**- Урам яктыртуын оештыруны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).**
**- Аксубай Урман заводы территориясендә үсентеләр чабу (ягулык-майлау материаллары сатып алу).**
**Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;**
**- Кышкы чорда автомобиль юлларын карап тоту (ягулык-майлау материаллары сатып алу, урамнарны кардан чистарту, килешү буенча эшләр өчен түләү).**

3. Әлеге карарны Кәкре Күл авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында http://aksubaevo.tatar.ru һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/бастырыпчыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Кәкре Күл авыл җирлеге башлыгы
ТР Аксубай муниципаль районы С. С. Елисеев